Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.07.2026 Менделеевск ш. № 478

Менделеевск муниципаль районында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибенә, шулай ук даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча транспорт чаралары хәрәкәте расписаниеләрен үзгәртү турында

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында "Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2026 елның 21 февралендәге 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 15 октябрендәге 705 номерлы карары белән расланган Менделеевск муниципаль районында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча транспорт чаралары хәрәкәте расписаниеләрен билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибенең 3 бүлеге 3.2 нче пунктында 9 нчы абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр кимрәк сроклар даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөрту һәм багаж ташу хокукы бирелгән юридик зат, шәхси эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы белән мондый хокукның гамәлдә булу срогы дәвамында килештерелмәгән булса, тиешле маршрутны аны билгеләгән вәкаләтле җирле үзидарә органы инициативасы белән үзгәртү йә туктату турындагы карар тәмамлану көненә кадәр 180 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә һәм мондый хокукның гамәлдә булу вакыты тәмамлангач үз көченә керә.»

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru,

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары

С.В. Метальниковка йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Искаков